МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.01.2017 г. Казань № 59 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ел саен үткәрелүче «Тантана» театраль конкурсы һәм премиясе турында нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 16 февралендәге 89 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ел саен үткәрелүче «Тантана» театраль конкурсы һәм премиясе турында нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 16 февралендәге 89 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык исемен «Тантана» сүзеннән соң («Триумф») сүзе белән тулыландырырга;

1 пунктта «10» цифрларын «12» цифрлары белән алыштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ел саен үткәрелүче «Тантана» («Триумф»)» театраль конкурсы һәм премиясе турында теркәлгән нигезләмәне расларга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Республика театрлары җитәкчеләренә театрның сәнгать советлары белән килештереп, Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге идарәсенә Нигезләмәдә билгеләнгән срокларга һәм таләпләргә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына документлар юлларга.»;

2. Боерыкка кушымтаны яңа теркәлгән редакциядә бәян итәргә;

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2011 ел, 16 февраль, 89 номерлы боерыгы белән расланган
(«24» 01.2017 ел №59 од боерык редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ел саен үткәрелүче «Тантана» («Триумф») театраль конкурсы һәм премиясе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ел саен бирелүче «Тантана» («Триумф») театраль премиясе (алга таба – Премия) профессиональ премия булып тора һәм җәмгыятьтә киң танылу алган театр сәнгате өлкәсендәге казанышлар өчен бирелә.

1.2. Премия Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ел саен бирелүче «Тантана» («Триумф») театраль премиясен бирү буенча Комиссия (алга таба – Комиссия) карары нигезендә тапшырыла.

1.3. Ел саен 17 февральгә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) массакүләм мәгълүмат чараларында премия бирүнең чираттагы конкурсы (алга таба – Конкурс) тәртибе һәм үткәрелү шартлары турында игълан итә.

## 2. Премиянең максатлары һәм бурычлары

2.1. Премиянең максаты – Татарстан Республикасында театр сәнгатенә дәүләт ярдәме.

2.2. Премиянең бурычлары:

Татарстан Республикасында театр сәнгате традицияләрен саклау һәм үстерү;

Татарстан Республикасында театр сәнгатенең төрле төрләре һәм жанрларында иҗади эшләрне ачыклау;

Татарстан Республикасында эшләүче талантлы театр әһелләрен бүләкләү;

Татарстан Республикасында бүгенге театр сәнгате казанышларын пропагандалау һәм популярлаштыру.

## 3. Премия номинацияләре

3.1. Премия конкурс нигезендә түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

«Дебют»;

«Иң яхшы эпизодик роль»;

«Иң яхшы курчак театры актеры»;

«Иң яхшы икенче пландагы хатын-кыз роле»;

«Иң яхшы икенче пландагы ир-ат роле»;

«Намус һәм ихтирам (Профессиягә тугрылык)»;

«Иң яхшы музыкаль спектакль роле»;

«Актерлар ансамбле»;

«Иң яхшы хатын-кыз роле»;

«Иң яхшы ир-ат роле»;

«Балалар өчен иң яхшы спектакль»;

«Ел вакыйгасы».

3.2. Премия алу өчен театр сәнгате үсешенә керткән өлеше әлеге Нигезләмәнең беренче пункты белән билгеләнгән һәм номинация эчтәлегенә туры килгән затлар тәкъдим ителә.

3.3. Премия персональ характерда. Бер үк затны Премиягә бер яки берничә номинация буенча тәкъдим итергә мөмкин.

## 4. Эшләрне бәяләү критерийлары

4.1. Премия алырга теләүчеләрнең эшләре «Намус һәм ихтирам (Профессиягә тугрылык)», «Ел вакыйгасы», «Балалар өчен иң яхшы спектакль» номинацияләреннән башка номинацияләрдә түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

образны югары сәнгати ачу;

актерның башкару осталыгы.

4.2. «Намус һәм ихтирам (Профессиягә тугрылык)» номинациясеннән башка номинацияләр конкрет спектакльдә актерның роль тудырудагы өлешен чагылдыра.

4.3. «Намус һәм ихтирам (Профессиягә тугрылык)» номинациясе актерлык биографиясе дәвамындагы иҗади өлеше өчен бирелә.

4.4. «Ел вакыйгасы» һәм «Балалар өчен иң яхшы спектакль» номинацияләрендә сәнгати бөтенлек, иҗади эзләнүләр берләштерелгән һәм тамашачының игътибарын яулаган резонанслы спектакльләр катнаша. «Ел вакыйгасы» һәм «Балалар өчен иң яхшы спектакль» номинацияләрендә премияне алырга теләүче булып спектакльне чыгаруда иҗади өлеше хәлиткеч роль уйнаган куючы иҗат төркеме (куючылар: режиссер, дирижер, балетмейстер, рәссам) санала.

## 5. Конкурс үткәрү тәртибе

5.1. Конкурс өч этапта үткәрелә:

Беренче – спектакльләрне тәкъдим итү;

Икенче – Премия алырга теләүчеләрне билгеләү;

Өченче – Премия номинантларын билгеләү.

**Беренче этап.**

5.2. Спектакльләрне тәкъдим итү хокукы түбәндәгеләргә бирелә:

Татарстан Республикасы тетар әһелләре берлеге (алга таба – Берлек);

Татарстан Республикасының дәүләт, муниципаль һәм хосусый театрларына (алга таба – театрлар).

5.3. Премьералары үткән елның 1 февраленнән иртәрәк булмаган һәм әлеге елның 1 февраленнән дә соңрак булмаган спектакльләр (алга таба – Эшләр) тәкъдим ителә.

5.4. Спектакльне тәкъдим итү өчен әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән театрлар һәм Берлек һәр календарь елының 28 февраленнән дә калмыйча 420015, Казан ш., Пушкин ур., д.66/33 (белешмәләр өчен телефон: 8 (843)2647444, 8 (843)2647453) адресы буенча Министрлыкның профессиональ сәнгать һәм һөнәри белем бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:

театрның атамасын, спектакльнең/спектакльләрнең исемен һәм премьераның төгәл датасын, «Намус һәм ихтирам (Профессиягә тугрылык)» номинациясе буенча премия алырга теләүчене күрсәтеп, ирекле формада язылган, җитәкче имзалаган һәм мөһер сугылган гариза;

теләсә кайсы электрон форматта спектакльнең тулы язмасы;

спектакльнең буклеты;

спектакль турында белешмә;

массакүләм матбугат чараларындагы язмалар.

**Икенче этап.**

5.5. Комиссия тәкъдим ителгән спектакльләрне карый.

5.6. Әлеге Нигезләмәнең 5.4. пунктында күрсәтелгән гаризалар тапшыру көненнән соң ун көн эчендә спектакльләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм аларның эшләрен Конкурсның өченче этабында карау өчен, Комиссия Премия алырга теләүчеләрне 15 мартка кадәр билгели.

Премия алырга теләүчеләр турында мәгълүмат Министрлык сайтына (http://mincult.tatarstan.ru) 15 марттан да соңга калмыйча урнаштырыла.

5.7. Икенче этап нәтиҗәләре буенча һәм Премия алырга теләүчеләр номинацияләр буенча билгеләнгәннән соң, спектакльләре номинацияләр буенча премиягә тәкъдим ителгән театрлар 15 марттан 20 мартка кадәр вакыт аралыгында Министрлыкның профессиональ сәнгать һәм һөнәри белем бүлегенә өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыралар:

Театр җитәкчесенең тәкъдим ителгән хезмәткәр турында түбәндәге мәгълүматны туплаган тәкъдимнамәсе: анкета мәгълүматы, тулы иҗади характеристика, булган дәрәҗә-бүләкләре, тәкъдим ителгән роль/спектакль турында белешмә, спектакльдән фоторәсем (5 данә), актерның фоторәсеме, массакүләм мәгълүмат чараларында

яктыртылу һәм мәкаләләр, хезмәткәрне премиягә тәкъдим итү турында театр җитәкчелегенең хаты;

премия алырга теләүченең паспорты, хезмәт кенәгәсе, ИНН бирелү турында таныклыгы, дәүләт пенсиясен иминиятләштерү турында таныклык күчермәсе[1].

Тапшырыла торган барлык документлар әлеге премия алырга теләүче хезмәткәр эшләгән театр җитәкчесе имзасы белән раслана.

5.8. Документлар Комиссия секретаре тарафыннан кабул итеп алына, Конкурска тапшырылган документларның тулы булуын тикшерелә.

5.9. Әлеге Нигезләмәнең 5.3, 5.4, 5.7 пунктларында билгеләнгән срокларны бозып юлланган гаризалар Конкурска кертелми.

Гаризага әлеге Нигезләмәнең 5.4, 5.7 пунктларында күрсәтелгән документлар теркәлмәгән булса, әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктларында күрсәтелгән театрлар һәм Берлек, әлеге Нигезләмәнең 5.4, 5.7 пунктларында билгеләнгән вакыт чыкканчы җитешмәгән документларны китерергә хокуклы.

**Өченче этап.**

5.10. Комиссия өч эш көне эчендә 5.7 пунктта күрсәтелгән документларны карый һәм 23 мартка кадәр Премия номинантларын билгели.

5.11. Премия алырга теләүчеләрнең тәкъдимнамәләре һәм документларына экспертиза әзерләү һәм үткәрү белән бәйле эшчәнлекне оештыру, мәгълүмати, документацион һәм хокукый яктан тәэмин итү, шулай ук аларны тикшергәннән соң Комиссия каравына тапшыруны Министрлыкын профессиональ сәнгать һәм сәнгати белем бүлеге тормышка ашыра.

5.12. Комиссия Премия номинацияләрендә җиңүчеләрне 26 мартка кадәр билгели.

## 6. Комиссия эшен формалаштыру һәм оештыру

6.1. Комиссия театр тәнкыйтьчеләре, театр, сәнгать, музыка һәм әдәбият белгечләре, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән төзелә.

Комиссия рәис, секретарь һәм Комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия рәисе Татарстан Республикасы мәдәният министры була.

6.2. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана.

6.3. Комиссия эше утырышларда тормышка ашырыла. Комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми саныннан өчтән икедән дә ким булмаган өлеше катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы булып санала.

6.4. Комиссиягә түбәндәге функцияләр йөкләнә:

Конкурс үткәрелү турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү;

Бирелгән документлар, видеоматериаллар нигезендә һәм спектакльләрне карап премиягә дәгъва итүчеләрнең эшләрен бәяләү.

---

[1] Персональ мәгълүматны эшкәртергә рөхсәт

6.5. Комиссия эше белән Комиссия рәисе идарә итә.

6.6. Комиссиянең җаваплы секретаре Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана, утырышларда тавыш хокукыннан башка гына катнаша, комиссия составына керми һәм түбәндәге функцияләрне башкара:

Әлеге Нигезләмәнең 5.4 һәм 5.7 пунктларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Эшләр теркәлгән гаризаларны кабул итә һәм терки;

Комиссия утырышларында карау өчен материаллар әзерли;

Комиссия утырышларын оештыра;

Конкурска тапшырылган документларның тулы комплектта булуын тикшерә;

Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен тутыра.

6.7. Һәр номинация буенча премия бирү турында Комиссия карары аның утырышта катнашкан әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч роль уйный. Комиссия әгъзаларының Рәсми бүләкләү тантанасына кадәр премия бирү турында карар турында хәбәр итергә хакы юк.

6.8. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышлары беркетмәләре Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

6.9. Комиссия карары бары тик суд тәртибендә генә яңадан карала ала.

## 7. Премия лауреатларын бүләкләү

7.1. Премиягә лаек булган затка Премия лауреаты дипломы һәм акчалата бүләк тапшырыла.

Бер номинация буенча ике яки аннан да күбрәк затка Премия тапшырылган очракта, акчалата бүләк бер үк номинация лауреатлары арасында тигез итеп бүленә, ә Премия лауреаты дипломы һәр лауреатка тапшырыла.

7.2. Премияләр «Галиәсгәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесендә Рәсми бүләкләү тантанасында Татарстан Республикасы мәдәният министры тарафыннан ел саен 27 мартта тапшырыла.